КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 апрель г.Казань № 268

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чистай муниципаль районындагы «Балкыш» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексны үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында

Социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 1 июленнән «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау миистрлыгының Чистай муниципаль районындагы «Балкыш» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексны үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – «Балкыш» үзәге) 20 койка-урынлы социаль-тернәкләндерү бүлеген бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә «Балкыш» үзәге тарафыннан әлеге учреждение структурасын оптимальләштерү буенча чаралар үткәрелгәндә хезмәткәрләргә карантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына оператив идарә итү хокукында «Балкыш» үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең аерым төрләрен алга таба файдалану турында тәкъдимнәр тапшырырга, әлеге мөлкәт исемлеге белән;

«Балкыш» үзәге тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә каралган чыгымнар өлкәсендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план

чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 ел, 21 ноябрь, ТР-88 нче Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча кысаларында «Балкыш» үзәге структурасын оптимальләштерү белән бәйле чараларны үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Календарь көннәрендә исәпләнгән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә элек «Балкыш» үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тапшырган мөлкәт исемлеге нигезендә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. «Балкыш» үзәге структурасын оптимальләштерү чараларын үткәргәннән соң азат ителә торган акча Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмаган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә халыкка социаль хезмәт күрсәтү тармагында социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарын компенсацияләүгә (кайтаруга) субсидияләр рәвешендә гарантлар бирүгә юнәлтелә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 ел, 21 ноябрь, ТР-88 нче Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән чаралар тәмамланганнан соң календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында Татарстан Республикасының тиешле норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин